**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4327**
**26.05.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 21 гыйнварындагы 224 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 21 гыйнварындагы 224 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6.1 пунктның 12 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.3.2.1 пунктта 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза

бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов